ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЛМИЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

“17” ноябрь 2025 ел Калмия авылы №13

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Калмия авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы , Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге Советы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында 2019 елның 30 октябрендәге 9/2 карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылында 2025 елның 27 ноябрендә 10.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылы территориясендә 2026 елда балигъ булган, Калмия авыл җирлегенең Малтабар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә1000 (Бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 ( биш йөз ) сум күләмендә билгеләргә һм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны,аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- урамнарны яктырту җайланмасы (яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру );

- торак пункт территориясен төзекләндерү (кече архитектура формалары , балалар өчен уен, спорт җиһазлары, вазоннар, коймалар, хуҗалык блогы, балалар мәйданчыгын каплау өчен ком сатып алу,махсус аренда. техника, материаллар сатып алу)

“ӘЙЕ” “ЮК”.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Малтабар авылы, Октябрьская урамы , 12Б йорты адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.

4. Тукай муниципаль районы Калмия авыл җирлеге башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Калмия авыл җирлеге Башлыгы Р.Р.Закиров